СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.01.2016 г. с. Шеланга № 6-36

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Шеланга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Шеланга авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 19 декабрендәге 5-30 номерлы Шеланга авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2016 елның 19 декабрендәге 2 номерлы Шеланга авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. 2016 елның 6 мартына Шеланга авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларның түбәндәге эшләрне башкару юнәлешендә җибәрелүе белән килешәсезме:

- Шеланга авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә 30 данә контейнер мәйданчыклары төзү, 150 данә контейнер сатып алу, гомуми суммасы 418 200 сум.

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырып чыгарырга, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге
башлыгы В.В.Майоров